# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында"
Татарстан Республикасы Законына
үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2009 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында" 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбуланы төшереп калдырырга;

2) 1 – 4 статьяларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1 статья. **Төп төшенчәләр**

Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) әлеге Законда кулланыла торган "коррупция" , "коррупциягә каршы көрәш" төшенчәләре "Коррупциягә каршы көрәш турында" Федераль закондагы мәгънәләрендә кулланылалар;

2) Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәте – Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәт субъектларының үз вәкаләтләре чикләрендә коррупциягә каршы көрәшкә һәм аның тискәре йогынтысын киметүгә юнәлдерелгән эшчәнлеге;

3) дәүләт органы – дәүләт аппаратының Татарстан Республикасы законнары нигезендә оештырылган, тиешле компетенция һәм аннан чыга торган структура бирелгән, үзенә хас оештыру-хокукый рәвешләрдә дәүләт-хакимият вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы состав өлеше.

### 2 статья. **Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтенең бурычлары**

Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтенең бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) коррупция сәбәпләрен ачыклау һәм юкка чыгару, аның чагылышына китерә торган шартларга каршы көрәш;

2) дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең законлылыгын һәм хәбәрдарлыгын тәэмин итү, аны дәүләт һәм иҗтимагый контрольдә тотуны тәэмин итү;

3) физик һәм юридик затларның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагыла торган мәсьәләләрне хәл итү процедураларын камилләштерү;

4) коррупциячел тәртипнең хәтәр булуын һәм аннан килгән югалтуларны арттыру;

5) закон кысаларында һәм иҗтимагый мәнфәгатьләрдән чыгып кылынган гамәлләрдән файда күрүне арттыру;

6) гражданнар җәмгыяте институтларын коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыруга җәлеп итү;

7) җәмгыятьтә коррупциягә карата тискәре караш формалаштыру.

### 3 статья. **Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтенең төп принциплары**

Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтенең төп принциплары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) гражданнарның һәм юридик затларның төп хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тану, тәэмин итү һәм яклау;

2) законлылык;

3) дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең хәбәрдарлыгы һәм ачыклыгы;

4) сәяси, оештыру, мәгълүмат-пропаганда, социаль-икътисадый, хокукый, махсус һәм бүтән чараларны комплекслы куллану;

5) коррупцияне профилактикалау чараларын өстенлекле куллану;

6) Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте яисә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның федераль законнар нигезендә хокукларын һәм ирекләрен чикләүгә юл куюны тану;

7) дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының гражданнар җәмгыяте институтлары һәм физик затлар белән хезмәттәшлеге.

### 4 статья. **Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәте субъектлары**

Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәте субъектлары булып түбәндәгеләр тора:

1) дәүләт органнары;

2) җирле үзидарә органнары;

3) Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру буенча махсус дәүләт органы;

4) коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру бурычларын үз вәкаләтләре чикләрендә хәл итүгә җәлеп ителгән оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр һәм физик затлар;

5) массакүләм мәгълүмат чаралары.";

3) 5 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

4) 6 статьяда "Россия Федерациясе Конституциясе," сүзләреннән соң "федераль конституциячел законнар, халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормалары һәм Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре," сүзләрен өстәргә;

5) 2 бүлекне үз көчен югалткан дип танырга;

6) 3 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3 бүлек. **Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен тәэмин итүнең төп чаралары**";

7) 3 бүлектә түбәндәге эчтәлекле $8^1$ статья өстәргә:

"$8^1$ статья. **Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен тәэмин итүнең төп чаралары**

1. Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәте түбәндәге төп чараларны гамәлгә ашыру юлы белән тәэмин ителә:

1) коррупциягә каршы республика, ведомство һәм муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру;

2) коррупциягә каршы экспертиза;

3) коррупциягә каршы мониторинг;

4) коррупциягә каршы белем бирү һәм пропаганда;

5) коррупциягә каршы көрәш буенча иҗтимагый эшчәнлеккә дәүләт ярдәме;

6) дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең хәбәрдарлыгын һәм мәгълүмати ачыклыгын тәэмин итү;

7) дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеген хокукый регламентлаштыру;

8) Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәте субъектлары тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә коррупциягә каршы көрәш турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән каралган бүтән чараларны гамәлгә ашыру.

2. Коррупциячел хокук бозуларны ачыклау, кисәтү, чик кую, ачу һәм тикшерү эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла һәм әлеге Закон предметы булмый.";

8) 9 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Татарстан Республикасының коррупциягә каршы программасы республика максатчан программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән тәртиптә эшләнә һәм гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасының коррупциягә каршы программасы проекты ачыктан-ачык фикер алышу өчен массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырылырга мөмкин.";

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Ведомствоның коррупциягә каршы программалары һәм (яисә) планнары билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары тарафыннан эшләнә һәм гамәлгә ашырыла.";

в) 4 өлештә "җирле үзидарә" сүзләре алдыннан "муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының" сүзләрен өстәргә;

9) 10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10 статья. **Коррупциягә каршы экспертиза**

1. Коррупциягә каршы экспертиза үткәрү дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның норматив хокукый актларында (норматив хокукый актлар проектларында) коррупция чагылышы өчен шартлар тудыра торган нигезләмәләрне ачыклау эшчәнлегеннән гыйбарәт.

2. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан закон чыгару инициативасы тәртибендә кертелүче федераль закон проектларына, Татарстан Республикасы законнары проектларына, Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларына, Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары, бүтән органнар һәм оешмалар тарафыннан эшләнә торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының кеше һәм гражданның хокукларына, ирегенә һәм бурычларына кагыла торган, оешмаларның хокукый статусын билгеләүче яисә ведомствоара характерга ия булган норматив хокукый актларына коррупциягә каршы экспертиза федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән методика нигезендә үткәрелә.

3. Дәүләт органнары һәм оешмалар үзләре кабул иткән норматив хокукый актларга (норматив хокукый актлар проектларына) коррупциягә каршы экспертизаны федераль законнар нигезендә аларда билгеләнгән тәртиптә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән методика нигезендә үткәрәләр.

4. Җирле үзидарә органнары үзләре кабул иткән норматив хокукый актларга (норматив хокукый актлар проектларына) коррупциягә каршы экспертизаны федераль законнар нигезендә аларда билгеләнгән тәртиптә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән методика нигезендә үткәрәләр.

5. Министрлыклар, ведомстволар һәм җирле үзидарә органнары үзләре әзерләгән хокукый акт проектына яисә үзләре чыгарган хокукый актка коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдим кертергә хокуклы.

6. Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру буенча махсус дәүләт органы коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында карар кабул итәргә вәкаләтләр бирелгән органнарга һәм оешмаларга норматив хокукый актларга коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында тәкъдим кертергә мөмкин.

7. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре норматив хокукый актларны (норматив хокукый актлар проектларын) эшләүчеләр тарафыннан катгый тәртиптә карала.";

10) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"11 статья. **Коррупциягә каршы мониторинг**

1. Коррупциягә каршы мониторинг – коррупцияне, аның чагылышы шартларын, коррупциягә каршы көрәшне һәм коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру чараларын күзәтү, анализлау һәм фаразлау эшчәнлеге, шул исәптән аларның Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтенең нәтиҗәлелеген бәяләү максатларында гамәлгә ашырыла торган социаль диагностикасы.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең Татарстан Республикасында коррупциягә каршы мониторинг үткәрүгә вәкаләтле башкарма органы һәм мондый мониторингны үткәрү тәртибе Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасында коррупция торышының аерым мәсьәләләре буенча җәмәгатьчелек фикеренә социаль тикшерүләр үткәрү турында, шул исәптән Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру буенча махсус дәүләт органы тәкъдиме буенча, карар кабул ителергә мөмкин.";

11) 12 статьяда:

а) статьяның исеме татарча үзгәрешсез кала;

б) 1 өлештә "дәүләт мәгариф стандартларының милли-региональ компоненты кысаларында эшләнгән һәм" сүзләрен төшереп калдырырга;

12) 13 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"13 статья. **Коррупциягә каршы көрәш буенча иҗтимагый эшчәнлеккә дәүләт ярдәме**

1. Коррупциягә каршы көрәш буенча иҗтимагый эшчәнлеккә дәүләт ярдәме күрсәтү устав максатлары һәм бурычлары сыйфатында коррупциягә каршы көрәшне гамәлгә ашыра торган иҗтимагый берләшмәләр формалаштыруны стимуллаштыруга, ныгытуга һәм үстерүгә, шулай ук башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм гражданнар җәмгыяте институтларының коррупциягә каршы

көрәш эшчәнлегенә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чаралар җыелмасын үз эченә ала.

2. Коррупциягә каршы көрәш буенча иҗтимагый эшчәнлеккә дәүләт ярдәме күрсәтү законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.";

13) 14 статьяда:

а) статьяның исемендә "хисаплар" сүзләреннән соң "һәм мәгълүматлар" сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 1[1] өлеш өстәргә:

"1[1]. Җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру буенча махсус дәүләт органына коррупциягә каршы сәясәт чараларын гамәлгә ашыру турында мәгълүмат тапшырырга хокуклы.";

в) 2 өлештә "әлеге Законның коррупциягә каршы сәясәт субъектлары өчен үтәлүе мәҗбүри булган нигезләмәләренең" сүзләрен "коррупциягә каршы көрәш буенча федераль законнарның һәм Татарстан Республикасы законнарының коррупциягә каршы сәясәт субъектлары өчен үтәлүе мәҗбүри булган таләпләренең" сүзләренә алмаштырырга;

г) 3 өлештә "Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне" сүзләрен "Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен" сүзләренә алмаштырырга;

14) 4 бүлекнең исемендә "Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне" сүзләрен "Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен" сүзләренә алмаштырырга;

15) 15 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"15 статья. **Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтенең оештыру нигезләре**

1. Татарстан Республикасы Президенты коррупциягә каршы сәясәт өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлегенә җитәкчелек итә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы коррупциягә каршы сәясәт өлкәсендәге Татарстан Республикасы законнарын эшләүне һәм кабул итүне тәэмин итә, шулай ук үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары эшчәнлеген тикшереп тора.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының коррупциягә профилактикалау буенча эшләрен берләштерә һәм аларга юнәлеш бирә.

4. Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру өлкәсендәге эшчәнлекне оештыруны, Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана торган нигезләмәгә таянып, махсус дәүләт органы гамәлгә ашыра.

5. Дәүләт органнарында аларның җитәкчеләренең хокукый актлары белән коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәтенең махсус бүлекчәләре төзелә яисә кадрлар хезмәтенең вазыйфаи затлары билгеләнә, аларның функцияләре Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

6. Җирле үзидарә органнары коррупцияне профилактикалау эшчәнлеген оештыру мәсьәләләрен федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә хәл итә.";

16) 16 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"16 статья. **Киңәшү һәм эксперт органнары**

1. Татарстан Республикасы Президенты карары буенча дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, фәнни, белем бирү учреждениеләре һәм башка оешмалар вәкилләре һәм коррупция мәсьәләләрен өйрәнүдә махсуслашкан затлар составында республиканың киңәшү һәм эксперт органнары формалашырга мөмкин.

2. Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәте субъектлары кызыксынучы дәүләт органнары, иҗтимагый берләшмәләр, фәнни, белем бирү учреждениеләре һәм бүтән оешмалар вәкилләре һәм коррупция мәсьәләләрен өйрәнүдә махсуслашкан затлардан торган киңәшү һәм эксперт органнарын оештыра алалар.

3. Киңәшү һәм эксперт органнарының вәкаләтләре, аларны формалаштыру һәм аларның эшчәнлеге тәртибе, шәхси составы тиешенчә үзләре каршында аларны төзи торган Татарстан Республикасы Президенты, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан раслана.";

17) 17 статьяның исемендә һәм текстында "Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне" сүзләрен "Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Ш. Шәймиев

**Казан, Кремль**
**2010 елның 19 гыйнвары**
**№ 6-ТРЗ**